# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

## Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Шилангы авыл җирлегенең Берек торак пунктында 2025 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында

2024 елның 28 ноябреннән №17

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Шилангы авыл җирлегенең Берек торак пунктында гражданнар җыены
КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Шилангы авыл җирлегенең Берек торак пунктында 2025 елда, гражданнарның түбәндәге категорияләреннән тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 1850 сум күләмендә үзара салым кертергә:
а) Бөек Ватан сугышы инвалидлары;
б) Бөек Ватан сугышында катнашучылар.
в) СВО катнашучылары гаиләләре

Аерым категория гражданнар өчен түләү күләме гражданнар җыены турындагы карарда билгеләнгән сумманың 50 процентын тәшкил итә:
а) 1нче төркем инвалидлар,
б) күп балалы гаиләләр,
в) көндезге уку йортлары студентлары,
г) Бөек Ватан сугышы ветераннары.

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

- Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарихи һәм мәдәни ядкарьләре) булмаган һәйкәлләрне төзү, ремонтлау һәм алар янәшәсендәге территорияне төзекләндерү.

3. Әлеге карарны Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында, Шилангы авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

Халык җыенында рәислек итүче,
Югары Ослан муниципаль районының
Шилангы авыл җирлеге башлыгы В.В.Майоров